**СОВЕТ БЕРЕЗКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422712, Республика Татарстан, Высокогорский район, С.Березка, ул.Новостройка, д. 15А

**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КАЕНЛЫК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422712, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Каенлык авылы, Новостройка ур, 15А

Тел./факс: +7(84365) 73-5-05, e-mail: Chern.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** | **КАРАР**

**30 сентябрь 2020 г.** | **№ 5**

**Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлеге Советының 2018 елның 10 декабрендәге 40 нче номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Каенлык авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең бер кеше башкара торган башкарма орган сыйфатында коммерция эшчәнлеге алып бармаган оешма идарәсендә бушлай нигездә катнашуга яисә аның коллегиаль идарә органы составына керү өчен яллаучы (эш бирүче) вәкиленнән рөхсәт алу тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау турында» карарын гамәлдән чыгару турында**

2019 елның 16 декабрендәге 432-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнарын камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә, 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законның 48 статьясының 1 өлешенә, «Каенлык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Гамәлдән чыгарырга:

Каенлык авыл җирлеге Советының 2018 елның 10 декабрендәге 40 нче номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Каенлык авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең бер кеше башкара торган башкарма орган сыйфатында коммерция эшчәнлеге алып бармаган оешма идарәсендә бушлай нигездә катнашуга яисә аның коллегиаль идарә органы составына керү өчен яллаучы (эш бирүче) вәкиленнән рөхсәт алу тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау турында»гы карарын.

Каенлык авыл җирлеге Советының 2019 елның 20 июндәге 11 нче номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Каенлык авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең бер кеше башкара торган башкарма орган сыйфатында коммерция эшчәнлеге алып бармаган оешма идарәсендә бушлай нигездә катнашуга яисә аның коллегиаль идарә органы составына керү өчен яллаучы (эш бирүче) вәкиленнән рөхсәт алу тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау турындагы карарына үзгәрешләр кертү турында» карарын.

2. Әлеге карарны Каенлык авыл җирлеге Советының мәгълүмат стендларында, Биектау муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм Татарстан

Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң (халыкка җиткерелгәннән соң) үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге Башлыгы И.И.Гатауллин

**АҢЛАТМА ЯЗУЫ**

«Каенлык авыл җирлеге Советының 2018 елның 16 ноябрендәге 163 нче номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Каенлык авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең бер кеше башкара торган башкарма орган сыйфатында коммерция эшчәнлеге алып бармаган оешма идарәсендә бушлай нигездә катнашуга яисә аның коллегиаль идарә органы составына керү өчен яллаучы (эш бирүче) вәкиленнән рөхсәт алу тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау турында»гы карарын гамәлдән чыгару турында»гы Каенлык авыл җирлеге Советының Карары проектына

2020 елның 04 апреле Биектау т/юл стан. бистәсе

Минем тарафтан, Биектау муниципаль районы Советының юридик бүлеге Начальнигы тарафыннан, Каенлык авыл җирлеге Советының «Каенлык авыл җирлеге Советының 2018 елның 16 ноябрендәге 163 нче номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Каенлык авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең бер кеше башкара торган башкарма орган сыйфатында коммерция эшчәнлеге алып бармаган оешма идарәсендә бушлай нигездә катнашуга яисә аның коллегиаль идарә органы составына керү өчен яллаучы (эш бирүче) вәкиленнән рөхсәт алу тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау турында»гы карарын гамәлдән чыгару турында»гы карары проекты (текст буенча алга таба – Проект) эшләнде.

Проект 2019 елның 16 декабрендәге 432-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнарын камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә муниципаль хокукый актны законнарга туры китерү максатларында эшләнде.

Биектау муниципаль районы Советының
Юридик бүлеге начальнигы В.Д.Архипов